**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01 июль 2024ел. № 301

**Әтнә район башкарма комитетының «Бинаны торак бина, Торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 12 гыйнварындагы 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 15.08.2022 ел, № 1415 карарына, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында” 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар итә:

1. Әтнә район башкарма комитетының “Бинаны торак бина, Торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2022 елның 12 гыйнварындагы 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның преамбуласында “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында" 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән" сүзләре белән алыштырырга;

1.2. Административ регламентның 3.3.2.1 пунктның 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал гаризаның дөрес тутырылмаган электрон формасы кырын ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.".

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе А. Ф. Каюмов